**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.02.2025 Балык Бистәсе штп. № 40пи

2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын туклandыруны оештыру турында

Укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту максатларында, шулай ук укучыларның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын гамәлгә ашыру максатында, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 08.12.2004 №63-ТРЗ Татарстан Республикасы Законын үтәү максатыннан, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Санитар-эпидемиологик Кагыйдәләрне раслау хакында "27.10.2020 №32 карарына ярашлы рәвештә һәм норм СанПин 2.3/2.4.3590-20 “Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр", Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары тарафыннан өйдә укыту оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны түләүсез ике тапкыр туклануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеген дә кертеп, түләүсез ике тапкыр туклануны тәэмин итү тәртибен раслау турында» 01.02.2023 № под-183/23 боерыгы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем алучы балаларга туклану хезмәтләре күрсәтү контрактларының типик шартларын раслау турында»29.03.2023 №498 карары, «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны бушлай кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар туклануның уртача бәясен раслау турында» 04.09.2023 №1066, "Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларын финанслау турында "08.08.2017 №566, «2024-2026 елларга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 07.09.2023 №1099, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 20.10.2022 №1122, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында»20.10.2022 №1122 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»14.11.2022 №1213,

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.2025 елның 1гыйнварынан 2025 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары (алга таба - муниципаль гомуми белем бирү оешмалары) укучылары өчен кайнар аш әзерләүне оештырырга.

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә18 яшькә кадәрге балалары булган күпбалалы гаиләләрдән муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын бушлай кайнар ризык белән (иртәнге аш белән);

әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә мөмкинлекләре чикле балалар һәм инвалид балалар өчен бушлай ике тапкыр кайнар ризык белән;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль белем бирү оешмаларында, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрбиләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнар, махсус хәрби операциясе уздырыла торган зонага командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, шулай ук әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләренең гаиләләренннән (гаилә әгъзаларына), булган 1-11 сыйныф укучыларын түләүсез ике тапкыр кайнар ризык белән.

3. Өйдә индивидуаль укытуга күчерелгән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларның (шул исәптән инвалид балаларның) ике тапкыр кайнар туклануын коры паек белән яки Татарстан Республикасы бюджетының тиешле бюджет ассигнованиеләре булганда һәм алар чикләрендә өйдә белем алучыларны туклану белән тәэмин итү максатларында белем бирү оешмасына җиткерелгән бушлай ике тапкыр туклану бәясенә тиң акчалата компенсация белән алыштырырга, һәр уку көнендә:

-районның гомуми белем бирү оешмаларының йортта индивидуаль белем алуга күчерелгән, сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән (инвалид балаларны да кертеп) 1-4 сыйныф укучыларына 160 сум 43 тиен суммага;

-районның гомуми белем бирү оешмаларының йортта индивидуаль белем алуга күчерелгән, сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән (инвалид балаларны да кертеп) 5-11 сыйныф укучыларына 180 сум 00 тиен суммага.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарда күрсәтелгән максатларга муниципаль гомуми белем оешмалары чыгымнарының расланган сметалары

чикләрендә җирле бюджет ассигнованиеләре хисабына финанс чараларын вакытында бүлеп бирүне тәкъдим итәргә.

5. Муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- балаларның азык матдәләренә һәм энергиягә булган физиологик ихтыяҗлары, тәүлеклек туклану рационының калориялелеген бүлү нигезендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ашатуны оештыруны.

-балансланган туклану белән тәэмин итү өчен кайнар иртәнге ашка 5-11 сыйныф балалары өчен 78 сум 00 тиен, төшке ашка 1-4 сыйныф укучылары өчен көненә 91 сум 00 тиен, 5-11 сыйныф укучылары өчен көненә 102 сум 00 тиен, озайтылган көн төркеменә йөрүче балалар өчен көненә 33 сум 30 тиен күләмендә ата-аналар взносы җыюны тәэмин итәргә. Кайнар туклануны оештыруга ата-ана взносын җыю гомуми белем бирү оешмасының шәхси счетына акча күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла;

- ата-аналар җыелышларында ата-аналарга (законлы вәкилләргә) кайнар туклануны оештыруга ата-ана кертеме сыйфатында җыелган акчаларның тотылуы турында мәгълүмат җиткерергә.

6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында кайнар туклануны оештыру өчен хезмәт күрсәтүчеләрне сайлап алу «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 05.04.2013 №44-ФЗ Федераль закон нигезендә электрон аукцион үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

8. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 20.02.2025
№ 40пи карарына 1нче
кушымта

Балык Бистәсе муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр түләүсез туклану белән тәэмин ителә торган, составында 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалы күпбалалы гаиләләрдән булган укучылар саны

| **Муниципаль гомуми белем бирү оешмасының исеме** | **2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31декабренә кадәр түләүсез туклану белән тәэмин ителә торган, составында 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалы күпбалалы гаиләләрдән булган укучылар саны** | |
|---|---|---|
| | 1-4 сыйныфлар (Республика бюджеты хисабына) | 5-11 сыйныфлар (иртәнге аш + төшке аш) |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "1 нче Балык Бистәсе гимназиясе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 10 | 17 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «2 нче Балык Бистәсе урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 15 | 21 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Биектау төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1 | 3 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 3 | 9 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы | 5 | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| "Зур Мәшләк урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | | |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Югары Тегермәнлек урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 0 | 1 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Күгәрчен урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 0 | 2 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Котлы Бөкәш урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 4 | 0 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Масловка урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 2 | 0 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Шомбыт урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 3 | 5 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Корноухово төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 2 | 1 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Түбән Тегермәнлек төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1 | 1 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Урахча төп гомуми белем бирү | 3 | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | | |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Юлсубино төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 2 | 1 |
| БАРЛЫГЫ: | 51 | 64 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 20.02.2025
№ 40пи карарына 2нче
кушымта

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр түләүсез туклану белән тәэмин ителә торган инвалид һәм сәламәтлекләре чикле балалар турында мәгълүмат

| № | МӘГАРИФ ОЕШМАЛАРЫ | | Инвалид- балалар (кеше) | | ОВЗ (кеше) | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Урта гомуми белем бирү мәктәпләре | | 1-4кл. / йортта индивидуаль укыту | 5-11кл. / йортта индивидуаль укыту | 1-4 кл.(төшке аш) | 5-11 кл. |
| 1 | 1 | "1нче Балык Бистәсе гимназиясе" МБМУ | 4/0 | 6/0 | 0 | 2 |
| 2 | 2 | 2 нче Балык Бистәсе урта мәктәбе» МБМУ | 2/1 | 3/2 | 1 | 13 |
| 3 | 3 | " Балыклы Чүкәй урта мәктәбе» МБМУ | 0/0 | 1/1 | 0 | 0 |
| 4 | 4 | " Биектау урта мәктәбе» МБМУ | 0/0 | 0/0 | 0 | 0 |
| 5 | 5 | Олы Елга урта мәктәбе МБМУ | 1/2 | 3/0 | 1 | 2 |
| 6 | 6 | Зур Мәшләк урта мәктәбе МБМУ | 0/1 | 0/0 | 0 | 1 |
| 7 | 7 | Югары Тегерменлек урта мәктәбе МБМУ | 1/1 | 4/2 | 0 | 0 |
| 8 | 8 | Күгәрчен урта мәктәбе МБМУ | 1/0 | 2/0 | 0 | 0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 9 | 9 | Котлы Бөкәш урта мәктәбе МБМУ | 0/1 | 3/2 | 0 | 0 |
| 10 | 10 | Масловка урта мәктәбе МБМУ | 0/0 | 0/1 | 0 | 1 |
| 11 | 11 | Яңа Арыш урта мәктәбе МБМУ | 0/0 | 0/0 | 0 | 0 |
| 12 | 12 | Шомбыт урта мәктәбе МБМУ | 3/0 | 3/1 | 0 | 0 |
| | | Төп гомуми белем бирү мәктәпләре | | | | |
| 13 | 1 | Корноухово төп гомуми белем бирү мәктәбе МБМУ | 0/0 | 0/0 | 0 | 0 |
| 14 | 2 | Күки төп гомуми белем бирү мәктәбе МБМУ | 0/0 | 0/0 | 0 | 0 |
| 15 | 3 | Түбән Тегермәнлек мәктәбе МБМУ | 1/1 | 2/0 | 0 | 0 |
| 16 | 4 | Трой Урай төп гомуми белем бирү мәктәбе МБМУ | 0/0 | 0/0 | 0 | 0 |
| 17 | 5 | Уракчы төп гомуми белем бирү мәктәбе МБМУ | 1/0 | 0/0 | 0 | 1 |
| 18 | 6 | Шомырбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе МБМУ | 0/0 | 0/0 | 0 | 0 |
| 19 | 7 | Балтач төп гомуми белем бирү мәктәбе МБМУ | 0/1 | 0/0 | 0 | 1 |
| 20 | 8 | Ямаш төп гомуми белем бирү мәктәбе МБМУ | 0/0 | 1/0 | 0 | 0 |
| | | Инвалид- балалар | 14/8(и/о) | 28/9(и/о) | | |
| | | Сәламәтлекләре чикле балалар | | | 2 | 21 |
| | | Сәламәтлекләре чикле балалар (шул исәптән инвалид балалар) | 65/17 (и/о) | | | |
| | | Сәламәтлекләре чикле балалар (шул исәптән инвалид балалар) | 1-4 кл.: 14 (инв.)+4 (ОВЗ)=16 кеше.<br><br>5-11 кл.: 28(инв.)+21(ОВЗ)=66 кеше. | | | |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 20.02.2025
№ 40пи карарына 3нче
кушымта

## Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән булган бушлай ике тапкыр кайнар ризык белән тәэмин ителә торган укучылар саны

| Муниципаль гомуми белем бирү оешмасы исеме | Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән булган бушлай ике тапкыр кайнар ризык белән тәэмин ителә торган 1-11 сыйныф укучылар саны |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "1 нче Балык Бистәсе гимназиясе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 19 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «2 нче Балык Бистәсе урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 25 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Зур Мәшләк урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 4 |
| Татарстан Республикасы Балык | 6 |

| | |
|---|---|
| Бистәсе муниципаль районы "Котлы Бөкәш урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Масловка урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 3 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Корноухово төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 2 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Урахча төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 1 |
| Барлыгы: | 61 |